ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Югары Ослан муниципаль районының «Яр буе Моркваш авыл җирлеге» һәм «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Югары Ослан муниципаль районы составына керүче «Яр буе Моркваш авыл җирлеге» һәм «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VI өлеш); 2013, № 7; 2014, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары Ослан муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның
статусы турында» Татарстан Республикасы
Законына 1 нче кушымта

# «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 5 (40) – 18 (41) | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| 18 (41) – 35 (42) | - Лаеш муниципаль районы |
| 35 (42) – 41 (87) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 41 (87) – 37 (38) | - Апас муниципаль районы |
| 37 (38) – 22 (39) | - Кайбыч муниципаль районы |
| 22 (39) – 5 (40) | - Зеленодольск муниципаль районы |

«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Иннополис шәһәре |
| 2 | Олы Мәми авыл җирлеге |
| 3 | Борнаш авыл җирлеге |
| 4 | Вахитов авыл җирлеге |
| 5 | Введенский Бистәсе авыл җирлеге |
| 6 | Югары Ослан авыл җирлеге |
| 7 | Канаш авыл җирлеге |
| 8 | Килди авыл җирлеге |
| 9 | Карагуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Куралово авыл җирлеге |
| 11 | Мәйдан авыл җирлеге |
| 12 | Макыл авыл җирлеге |
| 13 | Яр буе Морквашы авыл җирлеге |
| 14 | Түбән Ослан авыл җирлеге |
| 15 | Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге |
| 16 | Октябрь авыл җирлеге |
| 17 | Печище авыл җирлеге |
| 18 | Соболевский авыл җирлеге |
| 19 | Шылаңгы авыл җирлеге |
| 20 | Ямбулат авыл җирлеге |

»;

2) 14 нче кушымтаның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр буе Морквашы авыл җирлеге чиге Октябрь авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м көньяк-көнбатышка таба «Идел буе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ключище участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1 нче урман кварталының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 900 м бара, алга таба, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 350 м көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, алга таба, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 100 м көнбатышка

таба, 200 м көньякка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба бара, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,7 км төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, көньякка таба 400 м буа буенча, текә ярны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 70 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 100 м, яр буе агач-куаклык үсемлекләре полосасы буйлап 150 м бара, аннары, урман массивын һәм инешләрне кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 5 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 450 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 5 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 5 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 450 м көньякка таба 5 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 700 м көньякка таба 5 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары буа буенча 100 м төньяк-көнбатышка таба һәм 400 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 11 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 4,7 км төньяк-көнбатышка таба, 11 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,7 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 150 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 11 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 250 м көньякка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 11 нче урман кварталы буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 50 м һәм 11 нче урман кварталы буйлап 50 м бара, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм, инешне кисеп үтеп, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 500 м бара, аннары 11 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 30 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 11 нче урман кварталы буйлап 150 м төньякка таба уза, алга таба буа буенча 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары гомуми юнәлештә буаның көнчыгыш яры буйлап 150 м төньякка таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба бара, урман массивының көньяк чиге буйлап 150 м көнчыгышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м көнчыгышка таба, 300 м көньяк-көнчыгышка таба

уза, аннары, сынык сызык ясап, 12 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба бара, 11 нче урман кварталы буйлап 200 м көньяк-көнбатышка һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 12 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Казан – Ульяновск» – Никольский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 12 нче урман кварталы буйлап 50 м көнчыгышка таба бара, аннары 12 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 750 м көньяк-көнбатышка, 200 м төньяк-көнбатышка, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, зиратның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, алга таба зиратның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 30 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 16 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км бара, аннары 21 нче, 15 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба уза, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, берничә мәртәбә инешләрне кисеп үтеп, 15 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, алга таба 15 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка, 50 м көньякка, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, урман массивының төньяк чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 15 нче урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 2,2 км көнбатышка таба Яр буе Морквашы, Октябрь һәм Куралово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Никольский поселогыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

3) 17 нче кушымтаның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Октябрь авыл җирлеге чиге Яр буе Морквашы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Октябрь, Яр буе Морквашы һәм Югары Ослан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урман Морквашы авылыннан 1,4 км көнчыгышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м көньяк-көнбатышка таба «Идел буе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ключище участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1 нче урман кварталының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 900 м бара, алга таба, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 350 м көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, алга таба, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 100 м көнбатышка

таба, 200 м көньякка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба бара, инешне кисеп үтеп, 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,7 км төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, көньякка таба 400 м буа буенча, текә ярны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 70 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 100 м, яр буе агач-куаклык үсемлекләре полосасы буйлап 150 м бара, аннары, урман массивын һәм инешләрне кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 5 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 450 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 5 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 5 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 450 м көньякка таба 5 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 700 м көньякка таба 5 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары буа буенча 100 м төньяк-көнбатышка таба һәм 400 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 11 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 4,7 км төньяк-көнбатышка таба, 11 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,7 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 150 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 11 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 250 м көньякка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 11 нче урман кварталы буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 50 м һәм 11 нче урман кварталы буйлап 50 м бара, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм, инешне кисеп үтеп, 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 500 м бара, аннары 11 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 30 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 100 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 11 нче урман кварталы буйлап 150 м төньякка таба уза, алга таба буа буенча 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары гомуми юнәлештә буаның көнчыгыш яры буйлап 150 м төньякка таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба бара, урман массивының көньяк чиге буйлап 150 м көнчыгышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м көнчыгышка таба, 300 м көньяк-көнчыгышка таба

уза, аннары, сынык сызык ясап, 12 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба бара, 11 нче урман кварталы буйлап 200 м көньяк-көнбатышка һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 12 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Казан – Ульяновск» – Никольский автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 12 нче урман кварталы буйлап 50 м көнчыгышка таба бара, аннары 12 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 750 м көньяк-көнбатышка, 200 м төньяк-көнбатышка, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, зиратның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, алга таба зиратның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 30 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 16 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км бара, аннары 21 нче, 15 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба уза, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, берничә мәртәбә инешләрне кисеп үтеп, 15 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м бара, алга таба 15 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка, 50 м көньякка, 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, урман массивының төньяк чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 15 нче урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 2,2 км көнбатышка таба 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов


ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 24-ТРЗ

«Югары Ослан муниципаль районының
«Яр буе Моркваш авыл җирлеге» һәм
«Октябрь авыл җирлеге» муниципаль
берәмлекләре территорияләре чикләрен
үзгәртү һәм «Югары Ослан муниципаль
районы» муниципаль берәмлегенең һәм
аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында» Татарстан
Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына кушымта

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләр исәпкә алынган

<u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- Югары Ослан муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Яр буе Моркваш авыл җирлегенең һәм Октябрь авыл җирлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваш авыл җирлеге территориясе составына кертелә торган Югары Ослан муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге территориясе
- Югары Ослан муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге территориясе составына кертелә торган Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркваш авыл җирлеге территориясе